

# Аглиуллина Рәхимә Гыйльман кызы

**(16.03.1927 - 02.02.2001)**

Аглиуллина Рәхимә Гыйльман кызы 1927 елның 16 мартында Иләбәр авылында туа. 3 яшьтә ятим калып, үги әнкәй белән үсә. Иләбәр авылында 7 класс белем ала.  Ул 7 класс тәмамлаган елын сугыш башлана. Бөтен авырлыклар яшьүсмерләргә төшә: урман кисү, вагон төяү, торфка җибәрүләр... 1945 елда сугыш беткәч, Казандагы абыйсы үз янына алып китә. Анда кибеткә эшкә урнаша. Иләбәргә этисе янына кайтып йөри. Әтисе авырып киткәннән соң ,(3 елдан) Шәмәрдәнгә кайтып, кибеткә эшкә керә. 1953 елда Алан-Елга авылында Аглиуллин Хөснулла белән тормыш коралар. Шул ук елны  Шекше детдомына эшкә урнаша. Берничә елдан соң детдом ябыла. Аннан соң мәктәп буфетына эшкә урнаша, яңадан мәктәптә җыештыручы булып та эшли. 1977 елда лаеклы ялга чыга. 2001 нче елның 2 февралендә вафат була һәм Алан –Елга зиратына җирләнелә.

Кызы Зиннатова Райхана кулъязмасыннан.

9.04.2016



# Зәйнәгыева Гайшә Зәйнәгытдин кызы

**(10.09.1925 - 20.08.2006)**

Зәйнәгыева Гайшә Зәйнәгытдин кызы 1925 елның 10 сентябрендә Шекше авылында крестьян гаиләсендә туган.

Әтисе -Шәрәфиев Зәйнәгытдин, әнисе -Шәрәфиева Шәмсебаян. Ул, 7 классны тәмамлагач, “Якты юл” колхозында кырчылыкта эшли башлый.

1950 елда Сәрдә авылы егете Закиров Минсалихка кияүгә чыга, төрле эшләрдә колхозда эшли.

1953 елда ире фаҗигале рәвештә вафат була, һәм ул Свердловск өлкәсе Югары Пышма шәһәренә китә. Анда шактый еллар шахтада эшли, аннары пенсиягә киткәнче уенчык фабрикасында эшли, мактаулы эшче була.

2006 елның 20 августында вафат була һәм шул шәһәрдә җирләнә.

Зәйнәгыева Дулкыния кулъязмасыннан.

10.04.2016 ел

# Залялиева Газилә
# Мөбәрәкҗан кызы

**(17.12.1911 –7.12. 1990)**

Залялиева Газилә Мөбәрәкҗан кызы 1911 елның 17 декаберендә Алан-Елга авылында гади крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Үсә төшкәч, колхозда төрле эшләрдә эшли.

1936-37 елларда Шәмсетдин исемле егеткә кияүгә чыга, 1938 елда кызлары Нурия туа.

Шәмсетдин бабай сугышка хәтле вафат була. Төрле чыганаклар буенча, аны чәнчеп үтергәннәр. 1959 елда Газилә әби Галиәхмәт исемле егеткә кабат кияүгә чыга. Ул елларда “Якты Юл” колхозында эшләгән, Иштуган урманына урман кисүгә йөргәннәр, вагон бушатулар, алар бернинди эштән дә читтә калмаган.

1990 елның 7 декабрендә Газилә әби вафат була, Шекше зиратына җирләнә.

Газилә әбинең кызы Нурия, аның улы Рәис
Иләбәр авылында яши, Рәис кызы
Галимова Алисә кулъязмасы

11.04.2016



# Мирасова Мәфрүзә
# Мирас кызы

**(13.03.1924 –17.04.2011)**

Мирас кызы Мәфрүзә 1924 елның 13 мартында Алан-Елга авылында туган. Бала вакыттан авырлыкларны күп күргән. Тормышны җиңеләйтеү, акча эшләү максатыннан, этиләре Башкириягә эшкә киткән, шунда торырга урын табып, гаиләсен дә үз янына алган. Мондагы өйләрендә, алар кире кайтканчы, Зиннатова Гайҗамаллар яшәгән.

Мәфрүзә апа Алан-Елга мәктәбендә 3 класс укыган, аны Сәрдә Мәнзүмә апа укыткан. Үсмер чагында Пүкәл тегү артелендә эшләгән. Иштуганга менеп вагонга агач төягәннәр. Караңгыда, пычрак вакытта берүзе урман аша чыга торган булган. Соңыннан ул иске мәктәпкә җыештыручы булып урнашкан. Пөхтә, чиста булуы аркасында, аны гел мәктәп директоры мактаган. Ул чактагы мәктәп җыештыручысының эшен сөйләп бетерә торган булмаган.

1970 елларда медпунктта санитарка эшен башкарган, ул кулына укол тотып кына кадамаган, Сәрдә урманы аша ат белән дару ташу, укол кайнату, горчица, банка салу- Һәммәсе аның өстендә булган. Һәрбер кеше врач-хирург апа килә дип каршы алган. Перевязкага хәтле ясаган ул. 1979 елда пенсиягә шуннан чыккан.

Тормыш иптәше Нәфыйк абый үлгәннән соң, 20111 елга хәтле берүзе яшәде. 2011 елның 17 апрелендә гүр иясе булды, Алан-Елга зиратына җирләнде.



Мәфрүзә апа янында Шекше мәктәбе тимурчылары:

Гилязетдинов Булат
Габидуллин Ришат,
Габделхакова Айгөл,
Зиннатова Әдилә,
Галимов Илдар

28.01.2011

Аның тормыш юлын үзе сөйләгәннәрдән чыгып Мирасова Люция язды.

09.04.2016 ел



# Нотфуллина Сылубикә Галиәхмәт кызы

**(17.06.1921 –13.12.1981)**

Әниебез Нотфуллина Сылубикә Галиәхмәт кызы 1921 елның 17 июне көнне Байлар Сабасының Тукай урамында гади генә гаиләдә әтисе Галиәхмәт әнисе Зөһрәбикәне, апа-абыйларын сөендереп дөньяга килә. Матур, ишле, тулы гаиләдә яши әниебез. Мәктәп елларында бик сагынып, яратып искә ала торган иде. Әниебез танылган музыкант-композиторлар Аллаһияр һәм Хөснулла Вәлиуллиннар белән бер класста укый. Мәктәпне тәмамлагач, балалар бакчасына мөдир итеп билгеләнә. Бала-чага тавышы белән гөрләп торган балалар бакчасында абруйлы җитәкче-яраткан Сылу апага әйләнә әниебез. Районнан килгән өлгер , чибәр кызга авыл егетләренең күзе төшә, әмма әниебез авылның бер дигән тырыш, чибәр, өздереп җырлаучы егетен-әтиебез Тимершаехны сайлый һәм алар матур гына гаилә корып җибәрәләр.



Бөек Ватан сугышының ачы җилләре безнең гаиләгә дә тимичә калмый. Кадерле яраткан тормыш иптәшен сугышка озатканан соң, әниебез яраткан эшен тагын да авыррак эшкә, ферма мөдире эшенә алыштыра. Сугыш чорында авырлыкларны әниебез үз җилкәсендә татырга, күтәрергә туры килә...

Сугыш тәмамлангач, әтиебез белән матур гаилә тормышын дәвам итеп, 8 бала (5 кыз, 3 малай) тәрбияләп үстерәләр. Колхозда төрле эшләрдә мактаулы хезмәт күрсәтәләр. Әле хәтердә агитбригада концертларында шушы җырны җырлаулары:

Тимершаех белән Сылу
Берсеннән-берсе сылу.
Тагын кемнәргә эләгер
Алар күк алдын булу.

Әниебез “Ана даны” ордены, сугыш чорында күрсәткән югары хезмәтләре өчен медале һәм башка төрле медальләр, рәхмәт хатлары, Мактау Грамоталары белән бүләкләнә.

Кызганыч, әниебезнең гомере бик кыска булды. 1981 елның 13 декабре көнне әниебез бакыйлыкка күчте, Шекше зиратына җирләнде.



Әниебез!
Якты йолдыз булып син бакыйлыктан
Тормыш юлларыбыз күгендә.
Иң кадерле бер кешебез булып
Сакланырсың йөрәк түрендә!
Без әти-әниебезгә бик рәхмәтле.



Бу язма кызлары Гөлнур, Гөлнәзирә кулъязмасыннан.

11.04.2016



# Гиззатуллина Рабига Гыйльман кызы

**(....1923 –31.01.2007)**

Әгәр күк күгәрчен булсам,
Төшмәс идем һавадан;
Болай буласьмны белсәм,
Тумас идем анадан.

Рабига апа 1923 елда Шекше авылында яшәгән Гыйльман абый гаиләсендә унынчы кыз булып дөньяга килә. Үскәндә күп авырлыклар күрә ул. Репрессия газапларын да кичерә. Утызынчы еллар башында аларның бар булган мөлкәтләрен алып чыгып китләр, ягъни конфискациялиләр. “Өйдә бернәрсә дә калмады. Йоклаганда аска салам җәеп ята идек. Гаилә ишле булгач, ашарга җитмәдле. Чөгендер яфракларынннан күмәч пешерә идек. Абзарыбызга колхоз атларын алып килеп яптылар. Сакчы куйдылар, ул бөтен нәрсәне бикләп китә иде,”-дип искә ала Рабига апа ул шомлы елларны.

Аннары озак та үтми, илгә кара афәт- сугыш! Рәбига апа бу вакытта почта элемтәсе бүлеге начальнигы булып эшли башлаган була. Куанып кына йөргәндә, хезмәте белән кешеләргә күбрәк кайгылы хәбәр җиткерүче булып китә ул. Фронттан кара пичәтле хатлар килеп кенә тора. Ирләрен, улларын югалтканнарны юатырга сүзләр җитми. Җитмәсә, халыкны заем белән зар елаталар. Билгеле инде, Рабига апа кушканны үтәүче генә. “Кешеләр көндез эштә бит, төнлә бара идек өйләренә. Ишекләрен ачып керергә куркып тора идек,”-ди ул.

Рәбига апа Гыйззәтуллина җиңүне тизләтүгә үзеннән зур өлеш кертә. Төннәрен колхоз амбарында сортировкада эшли, көлтә кертә. Авылга эвакуацияләнеп килүчеләргә җылы киемнәр әзерлиләр, фатирларга урнаштыралар, ашарларына халыктан бәрәңге җыялар. Төп хезмәтендә дә сынатмый. Шекше элемтә бүлекчәсе района күп тапкырлар алдынгы була.

Эш, әни дип үз тормышы турында кайгыртырга вакыты да калмый Рәбига апаның. Йортта бөтен тормыш авырлыгы аның җилкәсендә була. Аларны бер-бер артлы үз гаиләләрен коралар. Ә төпчек кыз олыгайган әти-әнисенең төп ышанычына, таянычына әйләнә. Арба белән урманнан коры-сары ташып утын әзерли, хуҗалыктагы тавык чүпләп бетермәслек башка мәшәкатьләрне кайгырта. “Тормышка чыгарга сорап килүчеләр булмады түгел, булды. Әти-әнине караучы булмагач, кире борып җибәрә идек. Аларны ташлап китә алмадым.. Шулай итеп, кияүгә чыкмадым,”-ди Рәбига апа. Әнә шулай, әти-әнисе алдында мәңгелек бурычлы булу хисен барысыннан да өстенрәк күрә. Гомерен аларга багышлый.

Мәрхәмәтле, изге җан, риза-бәхиллекләрне алып, 1964 елда авыру әтисен, 1966 елда әнисен кадер-хөрмәт белән соңгы юлга озата. 1979 елда үзе дә. Эшләгән чорында бик күп бүләкләргә лаек булып, халык ихтирамын казанып, пенсиягә чыга. Авылдашларына 38 елпочта хезмәтен күрсәтүне оештыра ул. Әмма лаеклы ялда булуына карамастан, өйдә ялгыз моңаеп утырырга теләми. Күмәк хуҗалыкка булышудан үзенә куаныч таба. Унҗиде ел амбар эшенә йөри, чәчүлек бәрәңге ярып әзерләүдә катнаша.

Почта эшендәге уңышлары “Хезмәттәге батырлык өчен” медале белән бүләкләнә.

2007 нче елның 31 январенда вафат була һәм Шекше зиратына җирләнелә.



2007 елның 29 январь.

*Әгәр кцк кцгәрчен булсам,*
*Төшмәс идем һавадан;*
*Болай буласымны белсәм,*
*Тумас идем анадан.*

## Рәбига

Җәмгыять безгә олы вазифа — ата-аналар турында кайгырту, аларны тәрбияләү бурычын йөкли. Тормыш турында уйланганда яшәүнең моннан олырак мәгънәсе булмавына ышана башлыйсың. Чыннан да, арабызда бөтен гомерләре буе шушы олы бурычка тугрылыклы калган изге җаннар шактый безнең...

Рәбига апа 1923 елда Шекше авылында яшәгән Гыйльман абый гаиләсендә унынчы кыз бала булып дөньяга килә. Үскәндә күп авырлыклар күрә ул. Репрессия газапларын да кичерә. Утызынчы еллар башында аларның бар булган мөлкәтләрен алып чыгып китәләр, ягъни конфискациялиләр. “Өйдә бернәрсә дә калмады. Йоклаганда аска салам җәеп ята идек. Гаилә ишле булгач, ашарга җитмәде. Чүгендер яфракларыннан күмәч пешерә идек. Абзарыбызга колхоз атларын алып килеп яптылар. Сакчы куйдылар, ул бөтен нәрсәне бикләп китә иде”, — дип искә ала Рәбига апа ул шомлы елларны.

Аннары озак та үтми илгә кара афәт килә: сугыш! Рәбига апа бу вакытта почта элемтәсе бүлеге начальнигы булып эшли башлаган була. Куанып кына йөргәндә, хезмәте белән кешеләргә күбрәк кайгылы хәбәрләр ишеттерүче булып китә ул. Фронттан кара пичәтле хатлар килеп кенә тора. Ирләрен, улларын югалтканнарны юатырга сүзләр җитми. Җитмәсә, халыкны заем белән зар елаталар. Билгеле инде, Рәбига апа кушканны үтәүче генә. “Кешеләр көндез эштә бит, төнлә бара идек өйләренә. Ишекләрен ачып керергә куркып тора идек”, — ди ул.

Рәбига апа Гыйззәтуллина җиңүне тизләтүгә үзеннән зур өлеш кертә. Төннәрен колхоз амбарында сортиров-



када эшли, көлтә кертә. Авылга эвакуацияләнеп килүчеләргә җылы киемнәр әзерлиләр, фатирларга урна[illegible]ралар, ашарларына халыктан бәрәңге җыялар. Төп хезмәтендә дә сынатмый. Шекше элемтә бүлекчәсе районда күп тапкырлар алдынгы була.

Эш, әни дип үз тормышы турында кайгыртырга вакыты да калмый Рәбига апаның. Йортта бөтен тормыш авырлыгы аның җилкәсендә була. Апалары бер-бер артлы үз гаиләләрен коралар. Ә төпчек кыз олыгайган әти-әнисенең төп ышанычына, таянычына әйләнә. Арба белән урманнан коры-сары ташып утын әзерли, хуҗалыктагы тавык чүпләп бетермәслек башка мәшәкатьләрне кайгырта. “Тормышка чыгарга сорап килүчеләр булмады түгел, булды. Әти-әнине карачы булмагач, кире борып җибәрә идек. Аларны ташлап китә алмадым. Шулай [illegible] кияүгә чыкмадым”, — ди Рәбига апа. Әнә шулай, әти-әнисе алдында мәңгелек бурычлы булу хисен барысыннан да өстенрәк күрә. Гомерен аларга багышлый. Мәрхәмәтле, изге җан, риза-бәхиллекләрен алып, 1964 елда авыру әтисен, 1966 елда әнисен кадер-хөрмәт белән соңгы юлга озата. 1979 елда үзе дә, эшләгән чорында бик күп бүләкләргә лаек булып, халык ихтирамын казанып, пенсиягә чыга. Авылдашларына 38 ел почта хезмәтен күрсәтүне оештыра ул. Әмма лаеклы ялда булуына карамастан, өйдә ялгыз моңаеп утырырга теләми. Күмәк хуҗалыкка булышудан үзенә куаныч таба. Унҗиде ел амбар эшенә йөри, чәчүлек бәрәңге ярып әзерләүдә катнаша.

Почта эшендәге уңышлары “Хезмәттәге батырлык өчен” медале белән билгеләп үтелгән ветеран әле дә авылдашларының олы ихтирамын тоеп яши.

Рәбига апа турында язма ТР, Казан 2001, “Кыз әбиләр” китабында басылган.

Бу язманы Рабига апаның оныгы (Сагитов Илсур кызы) Сагитова Фәнүзә тапшырды.

9.04.2016



# Шәрипова Минниса


.............


**(....1924 –02.08.1977)**


## КҮПНЕ КҮРГӘН ӘНИЕМ

Үзең ничә яшьтә булсаң да, әниләрне югалту бик авыр. Күзләрен мәңгелеккә йомганда безнең әниебезгә нибары 53 яшь иде. Аннан башка яшәлгән 34 елның бер көне аны искә алмыйча уздымы икән? Мин әниемне һаман исән көе күз алдыма китерәм, аның белән киңәшәм, эчтән генә күңелдәге серләремне сөйлим. Без әниләрнең кадерен чын-чынлап белергә, аны хөрмәтләргә өлгерә дә алмый калдык. Йөрәкләрне үкенеч телгәли. Безне, 7 баланы үстерергә күпме көч, сабырлык, уңганлык кирәк булганын соңрак үзебез балалар үстерә башлагач кына аңлыйбыз шул. Ничек туйдырганнар, киендергәннәр, ничек укыткannар? Яшәү шартлары авыр чаклар бит. Бер мичкә якканда ниләр генә пешерми иде әни. Хуш исле арыш ипиенең тәме әле дә авызда кебек. Керосинкалар барлыкка килгәч, и сөенгән иде мәрхүмәкәй. Кечкенә балага сөт җылытасы яки манный пешерәсе булса да, өчаяк астына чыра ягып интегү түгел инде. Бераз гына кулланып калган баллонлы газны исә могҗизага тиңли иде. Бик тырыш, эшчән гаиләдә үскән әниебез. Кайберәүләр белән чагыштырганда житеш тормышта яшәгәннәр. 1931 елда аларны авыл куштаннары талый. Әнигә 7 яшь була. Дәү әнине идән астына бәрәңге тутырырга төшерәләр. Ә үзләре өйдәге әйбәтрәк әйберләрне җыеп алалар. Хәтта үлем түшәгендә яткан дәү әтинең баш астындагы ястыгын тартып алудан да тартынмыйлар. Дәү әти үлеп киткәч, тормышлары бик авырая әниемнәрнең. Аннары сугыш еллары газаплары башлана. Бервакыт Шәмәрдән янында урман кискән әнием иптәш кызы белән төнлә мунча керергә кайта. Ләкин юына алмый калалар: авыл Советы рәисе төрмә белән куркытып, урманга куа. Аннан соң әнине Мәскәүгә эшкә җибәрәләр. Элеваторда 70әр килолы капчыкны трап буйлап ташыганда, хәлсезләнеп егыла да, капчык аска төшеп ярыла. Ач халык ашлыкка ябырыла, ә әнине төрмәгә утыртып куялар. Әти белән әнием безгә бу хакта беркайчан да сөйләмәделәр. Сабыйлар дөрес аңламас дип уйлаганнардыр инде. Без бит элек төрмәдә начар кешеләр, бандитлар гына утыра дип уйлый идек...

Әниемнең истәлек дәфтәрләрен караганда аның төрмәдә язган шигырьләренә юлыктым. Шуны кыскартып, газета укучыларга да тәкъдим итәргә булдым.







Туганнарым, шагыйрь түгелмен мин,
Шагыйрь булмасам да мин язам.
Йөрәгемдә ниләр кайнаганын
Шигырьләрем аша аңлатам.
Төрмә...
Ерактан ук күренеп тора
Биш этажлы кызыл йорт.
Монда кайнар яшен түгә
Күпме гөнаһсыз халык.
Газиз әнием, мине беркайчан да Начар, диеп уйлама.
Чит җирләрдә башын җуяр,
Бу бала дип моңланма.
Җитәр инде, язмыйм инде,
Кулларым да талды, каләмем.
Сау булыгыз, туганнарым, җибәрәм кайнар сәламем.

Миңниса Хуҗина.

Бу юлларны мин елый-елый укыйм. Төрмәдән котылуга, әниебез авылга кайта һәм фронтовик әтиебезгә тормышка чыга. Алар бик тырышып, йортлар төзеп, мал-туар асрап, тату гомер иттеләр, 7 балага гомер бирделәр. Безне җил-яңгыр тидермичә үстерсә дә, үзен генә саклый алмады әни...

Язлар саен әнием каберенә барып, белгән догаларымны укыйм, күңелемнән аңа эндәшәм: тыныч йокла, әнием, әтиебез исән-сау, ул безне гомер буе кайгыртып яшәде. Аналар көнендә сине сагынып искә алабыз, ә әтиебезне котлыйбыз. Син күрә алмаган оныклар-оныкчыкларга куанып яшәсен әле, дибез.


Чәршәмбе, 7 март, 2012 ел, №18 (9631) «САБА ТАҢНАРЫ» www.tatmed

Хәтер-хатирә

КҮПНЕ КҮРГӘН ӘНИЕМ

Гүзәлия апаның “Күпне күргән әнием” мәкаләсе “Саба таңнары” газетасында басылган.
7 март, 2012 ел, №18 (9631)





Минниса апаның Мәскәүдә төшкән фотосы



Фотода: Хуҗин Әхмәт, Нәҗип абый, Минниса апа, кызлары Гүзәлия, кияүләре Рәшит




# Минниса апаның истәлек дәфтәре



















# Хөсәенова Сания Гыйззәт кызы

**(25.06.1927 - 21.01.2007)**

Хөсәенова Сания Гыйззәт кызы 1927 елның 25 июнендә Сәрдә авылында икенче бала булып дөньяга килә. Колхозлашу чоры башлангач, беренчеләрдән булып колхозга керәләр. Матур гына яшәгәндә, сугыш башлана. Барлык кешеләр кебек әни дә кайда кушсалар, шунда эшли: урман кисәргә дә бара, вагоннарга утыннар да төяп йөриләр.



1948 елда Шекше авылы егете Хөсәенов Гаҗибрахман белән гаилә коралар, 6 бала тәрбияләп үстерәләр. Колхозда эшләп пенсиягә чыга. 2007 елның 21 гыйнварында вафат була. Шекше авылы зиратыныаҗирләнә.

Кызы Зиннатова Әлфия апа кулъязмасыннан.

11.04.2016 ел



# Гыйләҗетдинова Фәүзия Ханнан кызы

**(1923 - 1.02.2009)**

Гыйләҗетдинова Фәүзия Ханнан кызы 1923 елда Сәрдә авылында туа. Ул сугыш чоры баласы була. Фәүзия кечкенәдән әнисенә булышып үсә. Яшьүсмер чактан ук авыл кибетенә сатучы булып эшкә керә. Аннан соң сыер савучы булып фермада гомер буе эшли. Фәүзия Ханнан кызы 2009 елның 1 февралендә вафат булып, Сәрдә авылы зиратына җирләнә.

Гыйләҗетдинова Зәлинә, 8 класс

11.04.2016 ел



# Гараева Зәкия Хисамутдин кызы

**(15.06.1913 –4.03.2010)**

Минем әбием Гараева Зәкия Хисамутдин кызы 1913 елның 15 июлендә Шекше авылында туган. Шул ук авылның мәктәбендә укыган. Ул ,7 еллык мәктәпне укып бетергәч ,Казанга тегүчелек һөнәренә укырга китә. Сугышка кадәр Казанда тегүче булып эшли. 1932 елны, авылга кайтып, Алан-Елга авылы егете Гараев Солтанга кияүгә чыга. Зәкия әбинең 5 баласы туа. Үзенең яшәү дәверендә трактористлыкка укып, тракторист булып та эшли. Сугыш беткәч, Шекше авылында балалар йортында тәрбияче булып эшли. Балаларны тегү һөнәренә өйрәтә. Детдом икече жиргә күчерелгәч, пенсиягә чыкканчы колхозда эшли. Зәкия әбигә лаеклы ялга киткәндә “Хезмәт ветераны” исемен бирәләр. Эшләү дәверенә бик күп истәлекле бүләкләр һәм медальләр белән бүләкләнә. Әлеге көндә дә аның медальләре саклана.



Бөек Ватан сугышында Жиңүнең 50 еллыгы медале.

Бөек Ватан сугышында Жиңүнең 55 еллыгы медале.

Бөек Ватан сугышында Жиңүнең 60 еллыгы медале.



Әбием Зәкия 2010 нчы елның 4 мартында вафат була һәм Алан –Елга зиратына жирләнелә.

Зәкия апаның улы Гараев Рафаэль абый сөйләгәннәрне оныгы, 6 класс укучысы Илсинә (фотода) язды.

11.04.2016 ел



# Таҗиева Масурура Сабиржановна

**(22.06.1920 –23.12.2002)**

Таҗиева Мәсрүрә Сабирҗан кызы 1920 елның 22 июнендә Алан-Елга авылында икенче бала булып дөньяга килгән. Бертуганнары Мөслимә, Майсара, Ширияздан. Шекше мәктәбендә 7 ел белем алган. Укып бетергәч, Алан-Елга егете Таҗиев Җиһангир Таҗи улына кияүгә чыга. Гаиләләре белән Чита шәһәренә китәләр. Мәсрүрә-тегүче, Җиһангир-тимер юл станциясендә поездлар җибәрүче булып эшлиләр. Бу вакытта аларның дүрт балалары: Бәшир, Марзыя, Разыя, Таһир дөньяга килә. 1946 елда кире Алан-Елга авылына тоз төягән вагонга утырып 1 ай кайтканнар. Авылга кайткач, тегүчелек эшен дәвам итә. Тагын 7 бала: Закир, Зөһрә, Дамирә, Әлфия, Кадыйр, Нурфия, Гөлфия дөньяга киләләр. Мәсрүрә Сабирҗан кызы “Ана даны ордены белән бүләкләнә. 2002 елның 23 декабрендә вафат була. Алан-Елга зиратына җирләнә.



25.04.2016 ел





# Тажиев Жиһангир
# Тажетдин улы

**(24.10.1912 -**



Тажиев Жиһангир Тажетдин улы 1912 елнны 24 октяберендә Алан-Елга авылында туып үсә, 22 яшенә кадәр авылда яши,аннан аны Четенский обл.Нечинский район село Верех.Ключей дигән обл.ка жибәрәләр. Ул анда берничә ел эшләгәч, кайтып өйләнә дә тагын китә, ул анда мастер железнодорожников булып эшли, сугыш башлангач, аны шул эшендә калдыралар, сугышка алмыйлар, железнодорожныйда эшләгәндә, аягына тимер керә, анын аягы бозылып ага башлый, ул шулай да эшен намус белән башкарып, сугыш беткәч, 4 бала, әни белән исән имин туган авылга кайталар. Әтине сарык фермасына завферма итеп куялар, күп кенә еллар анда эшли, аннан амбарда кладавчик булып эшли, хужалыкта сөт жыя, хужалыкта балта остасы, мич чыгарып йөреп авыл халкын сөендерә.



# Фатыйхова Кәүсәрия Абдулла кызы

**(18.07.1932 –28.07.2014)**

Әнием Фатыйхова Кәүсәрия Абдулла кызы 1932 елның 18 июлендә Шекше авылында дөньяга килә. Алар гаиләдә 4 бала: Кәүсәрия, Вагиз, Нәсим, Нәсимә. Нәсим 9 яшьлек вакытта суга батып үлә. Әнием мәктәптә бик әйбәт укый, ләкин алга таба укый алмый. Аңа 12 яшь вакытта әниләре үлә, бөтен авырлык аның җилкәсенә кала. Сугыш вактында әтисе сугышка китә, сугышның ахырына кадәр сугыша алмый, яраланып кайта. Ул озак еллар тракторда плугарь булып, кыш көне терлекчелектә эшли. 1953 елда авыл егете, Донбасста шахтада эшләгән Мираска кияүгә чыгып, Донбасска китәләр. 1956 елда кайнанасын тәрбияләү өчен кире авылга кайтып төпләнәләр. Алар 4 балага гомер бирә. Ләкин парлы тормыш озакка бармый. Әтием Мирас 1962 елның 2 сентябрендә кисәк вафат була. 4 баланы әнием ялгызы тәрбияли, аларга белем бирә. Өр-яңадан йорт җитештерә. Гомере буе колхозда хезмәт куя, терлекчелектә эшли: сарык та карый, таналар да үстерә, сыер да сава. Әтием үлгәннән соң 15 ел бергә яшәп, авыру кайнанасын тәрбияләп соңгы юлга озата.

Әнием Кәүсәрия 2014 елның 28 июлендә 82 яшендә вафат булып, Шекше зиратына җирләнә.

Алан-Елга авылында яшәүче кызы

Шарифуллина Сәвия кульязмасыннан.

12.04.2016



# Әхмәтшина Фәрхинур Гарәбша кызы

**(.... 1922 - 06.11.1990)**

Әхмәтшина Фәрхинур Гарабша кызы 1922 елда Шекше авылында туа. Ул гаиләдә берүзе тәрбияләнә. Энесе Тәлгать кечкенә вакытта үлә. Мәктәпне бик яхшы билгеләренә тәмамлаганнан соң, ул укытучы белеме үзләштерә. Аннары Үзбәкстандагы туганнары янына китә. Анда Бохара шәһәрендә укытучы булып эшли, тормышка чыга. Ләкин ул ире белән 9 ай гына яшәп кала, сугыш башлана. Сугышка алынып озак та үтми, иренең үлеме турында хәбәр килә. Фәрхинур үзе тиф авыруы йоктыра. Бик озак авыру белән көрәшергә туры килә аңа. Шул вакытта туачак баласын да югалта. Терелгәннән соң, 1942 елда туган ягына кайтырга чыга ул. Ләкин кайтып җитәргә насыйп булмый аңа. Ялгышлык белән поезд астында калып, бер аягы тубыктан өзелә, күп кан югалтып больницага эләгә. Аягын башта тездән, аннары төптән үк кисәргә туры килә. Бер аяк белән булса да, ул гомере буе кибеттә эшләп, халыкка хезмәт итте. Әти-әнисен тәрбияләп соңгы юлга озатты, яшәү өчен яңа йорт җиткерде.  1990 нчы елның 6 ноябрендә 70 яшендә вафат булып, Шекше авылында җирләнде.



Шарифуллина Сәвия кульязмасыннан.

12.04.2016



# Шәрифуллина Зәкиябану Тажетдин кызы

**(30.06.1922 –2.09.1977)**

Шәрифуллина Зәкиябану Тажетдин кызы 1922 елның 30 июнендә Алан-Елга авылында дөньяга килә. Алар гаиләдә өч бала үсә: Шәһәрбану, Җиһангир, Зәкиябану. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Зәкиябану колхозда эшли. Плугарь булып та, терлекчелектә дә эшләргә туры килә. Сугыш чорында ирләр сугышка китеп беткәч, бригадир булып та эшли әле ул. 1946 елда йөргән егете Хөснулла сугыштан кайта, алар өйләнешәләр, бригадирлык Хөснуллага күчә. 1947 елда кызлары Гөлсем, 1949 елда уллары Исмәгыйль туа. Алар барлыгы 7 бала үстерәләр. Зәкиябану колхозда төрле эшләрдә эшли. Башта кайнатасын, аннары 11 ел буе сукыр булып яшәгән кайнанасын тәрбияләп, соңгы юлга озата. Бик тырышлык белән зур итеп йорт җиткерәләр. Ләкин ул анда озак яши алмый, 1977 елның 2 сентябрендә каты авырудан 55 яшендә вафат була һәм Алан-Елга зиратында җирләнә.

Бүләкләре:

I, II, III дәрәҗә “Аны даны” медальләре;

1941-45 елларда фидакарь хезмәт өчен медале;

1970 елда Ленинның 100 еллыгына “За доблестный труд” медале;

1975 елда “Участник трудового фронта” медале.




Шарифуллина Сәвия

кулъязмасыннан.

12.04.2016



# Хаертдинова Бибигазизә Әшрәфҗан кызы

**(23.01.1910 –24.06. 1978)**

Хаертдинова Бибигазизә Әшрәфҗан кызы 1910 елның 23 январендә Шекше авылында крестьян гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Әтисе Әхмәтҗанов Әшрәфҗан, ә әнисе Бибикамилә исемле була.

Балачагы авыр, кырыс елларга туры килә. Бик яшьли “Якты юл” колхозында хезмәт итә башлый. 1934 елда шушы авыл егете Хаертдинов Габдрахман белән гаилә корып, матур гына гомер итәләр. Алар бер ул һәм ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Ачы сугыш афәте башланып, ире сугышка киткәндә, ике бала белән кала. Бу елларны ул бигрәкт ә ачынып искә ала иде. Һәм ни кызганыч, аның ире туган якларына кире әйләнеп кайтмый. Аңа өч баланы берүзенә тәрбияләп үстерергә туры килә. Ул үзенең кайнана һәм кайнатасын да олылап, тәрбияләп соңгы юлга озата. Ул 1978 елның 24 июнендә вафат була һәм Шекше зиратына җирләнелә.

Хаертдинова Йөзлебикә кулъязмасыннан.

12.04.2016



# Загретдинова Гөлбану Загретдин кызы

**(2.04.1914 –19.10.2005)**

Загретдинова Гөлбану Загретдин кызы 1914 елның 2 апрелендә Алан-Елга авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Сагитов Загретдин Сагит улы, әнисе Сагитова Мастура Биктимер кызы була.

Гөлбану яшь, матур, үткен кыз булып үсеп җитә. Шуннан ул Тимершык авылы егетенә кияүгә чыга. Ире сугышка китеп, аннан кире әйләнеп кайта алмый. Гөлбану Шәмәрдәндә электр станциясендә эшли башлый. Бу эш ирләр эше була. Бөтен хезмәт кул көче белән башкарыла. Яхшы хезмәте өчен зур исемнәр ала. Шунда эшләп, лаеклы ялга чыга, Шекшегә кайтып тора башлый. Туганнары тәрбиясендә 2005 елның 19 октябрендә бакыйлыкка күчә, Шекше зиратына җирләнә.



Фотода: сулдан Хаертдинов Ризван, Йөзлебикә, Йөзлебикә апаның абыйсы Рәшит, аның хатыны Рая, уртада Гөлбану апа, аның кулында кечкенә бала Хаертдинов Радик

Хаертдинова Йөзлебикә апа кулъязмасы

12.04.2016

# Загретдинова Гульзифа Загретдин кызы

**(21.09.1908 –30.03.1978)**

Загретдинова Гульзифа Загретдин кызы 1908 елның 21 сентябрендә Алан-Елга авылында дөньяга килә. Әтисе Сагитов Загретдин Сагит улы, әнисе Сагитова Мастура Биктимер кызы була.

Гөлзифа яшь, матур кыз булып үсеп җитә. Яшьли колхозда хезмәт итә. Алан-Елга авылының Нотфуллин Ахмадулла белән гаилә корып җибәрәләр. Гаиләләрен тулыландырып 3 кыз, 1 малайга гомер бирәләр. Балаларны тәрбияләп үстерү аның үз җилкәсенә төшә. Язмыш аны төрле яклап сыный һәм алма кебек ике кызын аяныч рәвештә югалта. Бала хәсрәтенең ачысын татырга туры килә. 1978 елның 30 мартында улына кунакка барган җирендә бакыйлыкка күчә һәм шунда җирләнә .

Хаертдинова Йөзлебикә кулъязмасыннан.
12.04.2016



# Әшрәпова Тәкмилә Хайрулла кызы

**(23.02. 1912 –23.02.1993)**

Минем әнием Әшрәпова Тәкмилә Хайрулла кызы 1912 елның 23 февралендә Эзмә авылында туган. Аның әтисе Хайрулла, әнисе Миңзифа булган. Алар дүрт кыз бала үстергәннәр.

Минем әнием 1936 елның 20 июнендә Шекшегә Әшрәфҗан улы Гарифҗанга кияүгә чыккан. 1937 елның сентябрь аенда Юнис абыем, 1939 елның 13 ноябрендә мин- Фәния туганмын. Безгә әти белән үсәргә һәм яшәргә насыйп булмады. Чөнки 1941 елның июнь аенда сугыш башлана һәм әтиебез сугышка китеп югала. Аның: ”Юлда барабыз, кая бару мәгълүм-бу сугыш,”-дип язган почтовая карточка белән килгән бер генә хаты бар. Шулай итеп, без ике бала әтисез, әниебез ирсез кала. Алар биш ел гына яшәп калалар. Яшь балалары булуга карамастан, әнине дә окоп казырга җибәрәләр. Әтинең әтисе Әшрәфҗан бабай белән әнисе Камилә әби безне карап торалар. Юк-бар өс-баш, чабата-оеклар белән, ачлы-туклы килеш окоп казыганнарын, куллары күшегеп, чабата киндерәләрен чишә алмыйча җәфаланганнарын сөйли иде әнием.

Сугыш беткәч тә, әти кайтмагач, әнигә бик авыр була тормыш итүе. Колхозда төрле эшләрдә эшләп, аннары мәктәптә җыештыручы булып эшли. Алар карлы-бозлы утыннарны кисеп, ярып, мичкә якканнар. Көн саен төн уртасында килеп, балалар килгәнче җылынырга, исе бетеп торырга тиеш була.



Әниемнең Бөек Ватан сугышы елларындагы намуслы хезмәте өчен һәм Бөек Җиңүнең 30 еллыгына карата бирелгән медальләре бар.

Мин әниемне бер рәхәт күрмичә дөньядан китте дип, кызганып искә алам. Ул 1993 елның 23 февралендә, үзенең 81 яшьлек туган көнендә гүр иясе булды. Ул Шекше зиратына җирләнде.

Урының оҗмахта булсын, кадерле әнием, зур рәхмәтләр белән каберең янында баш иям.

Кызың Әмирова Фәния. 12 апрель 2016 ел



# Мухамадиева Мамдуха Мухаммадиевна

**(21.06.1926 -**

В летний день 21 июня 1926 года в деревне Шикши Сабинского района в семье  Мирзагалямовых Мухамади и Латифы родилась старшая дочь Мамдуха. В день начала Великой Отечественной войны ей исполнилось 15 лет. Отец ушел на войну и не вернулся, погиб под Смоленском. И с тех пор началась её взрослая трудовая биография. В годы войны трудилась бригадиром, пришлось работать в тяжелых условиях, выполняя порой мужскую работу. В апреле 1953 года выходит замуж за уроженца той же деревни веселого, задорного красавца гармониста Зайнетдинова Вагиза, с которым вместе прожили красивую, счастливую жизнь – 55 лет, воспитали дочь и сына. В 1955 году семья переезжает на Урал, в город Кировград Свердловской области, где они до выхода на пенсию работали на Кировградском медеплавильном комбинате, ныне Производство полиметаллов АО «Уралэлектромедь»

За свою трудовую деятельность были награждения почетными грамотами и юбилейными медалями. Оба удостоены звания «Ветеран труда», а Вагиз Фасхиевич признан «Лучшим рационализатором комбината».

Оба являются трженикам тыла. У них 4 внука и 7 правнуков. К сожалению, Вагиз Фасхиевич умер, немного не дожив до 80 лет- светлая ему память. Семья Зайнетдиновых Вагиза-Мамдухи – достойный пример для подражания.





# Махмутова Хәдичә Арыслангали кызы

**(...02.1910 - 03.02.1984)**

Махмутова Хәдичә Арыслангали кызы 1910 елның февралендә Саба районы Өтернәс авылында дөньяга килә. “Тормышлар авыр иде без үскәндә, ашарга, кияргә булмады, “-дип сөйли иде ул. ”Бәхетле балачак” төшенчәсе ул елларда туган балаларга ят нәрсә булган. Апайларын туйдырырга тырышып , ул кечкенәдән үк төрле эшләрдә эшләгән. 1933 нче елны Шекше авылы егете Мәсъгут белән тормыш коралар. Алар 9 балага тормыш бирәләр. Рәхимсез сугыш башланганчы , 4 бала дөньяга килә. Сугыш тәмамлангач, тагын 5 бала таба. Авыр еллар Хәдичә әбине дә урап узмый. “Саимә” чишмәсеннән иртән торып суга бара, гаиләне туендыру өчен каз – үрдәк, сарык маллары асраулар ,9 баланы тәрбияләү, ашату, өстен – башын карау өстенә, “Якты юл” колхозында хезмәт куя. Кул белән урак урып, сугуны бик оста башкара Хәдичә әби. Ындыр табагында ашлык суырырга да катнаша. Аның фидакарь хезмәтләре өчен бирелгән мактау кәгазьләре һәм медальләре бар.

Әйе, ул елларда көнне-төнгә ялгап эшләүче, ачлыкны, ялангычлыкны күреп, җилкәләрендә ир-егетләр генә күтәрә алырдай эшләрне башкаручы , итәк тулы балаларына җылы бирүче ,туганнарына ныклы терәк була булучылар алар.



Махмутова Хәдичә 1984 елның 3 февралендә вафат була һәм Шекше зиратына җирләнелә.

Сөйләде кызы Халисә

Язып алды Махмутова Г. З

15.04.2016



# Шакирова Әминә Юсуп кызы

**(10.06.1914 –10.06.1997)**

Шакирова Әминә Юсуп кызы 1914 елның 10 июнендә Пүкәл авылында туа. 1937 елда Шекше авылына Шакиров Газизгә тормышка чыга. Матур гына яшәгәндә, сугыш башлана. Ире сугышка китә, ә әни 3 бала белән авылда кала. Олы кызы Нәсимә апа 4 яшьтә авырып үлә. Кайгы өстенә кайгы, иренең 1944 елда үле хәбәре килә. Балаларын  ач-ялангач итмәс өчен, көне-төне тырышып эшли, колхозда бөтен эш кул хезмәте белән башкарыла. Урак белән басуда көлтә ясыйлар, аннан ашлык уып алып кайтып балаларына киптереп ашата. Күп еллар яшелчә бригадиры булып эшли. Малын асрый, шулай итеп исән-имин калалар. Тагын әле ул район судында хөкем  ителүчене яклаучы булып сайлап куела. Анда да кешеләргә булышып ,күп еллар эшли. Аннан соң балалар кул арасына керә башлый. Шулай итеп авырлыклар белән тырышып яшәп ята. Ул 1997 елның 10 июнендә 82 яшендә бакый дөньяга күчә һәм Шекше зиратына җирләнелә. Урыны оҗмахта булсын.

Кызы Шакирова Флюра  кулъязмасыннан.

14.04.2016 ел




# Галиакберова Мәгъзүмә Мөхәммәт кызы

**(25.07.1930 –15.12.2015)**

Галиакберова Мәгъзүмә Мөхәммәт кызы 1930 елның 25 июлендә дөньяга килә. Сугыш башланганда, әнигә 11 яшь булган, этиләре сугышка киткәндә, әниләре кулында 7 бала калалар, иң кече энеләре туып кына калган. Әнигә колхозның бөтен эшләрендә катнашырга туры килгән. 14 яшендә сукада плугарь булып йөргәндә аягын сындыра. Сугыш беткәч, бабай (этиләре) сау-сәламәт авылга әйләнеп кайта. 1956 елга кадәр авылда яши, 1956 елда Казанга китеп төзелешкә эшкә урнаша. Соңыннан күп еллар Үзбәкстанда яшиләр. 1990 елларда Башкириягә кайтып урнашалар. 2007 елда Шекшегә кайтты һәм 2015 елның 15 декабренә кадәр яшәп, шушында вафат булды. Шекше зиратына җирләнде.



Кызы Нурания кульъязмасыннан.

14.04.2016 ел.

# Гатауллин Габдуллаҗан Гатаулла улы

Гатауллин Габдуллаҗан  Гатаулла улы 1891 елда Саба районы Бөкмеш авылында имам гаиләсендә туа. Бер абыйсы гражданнар сугышында һәлак була. 1937 елда Гатаулла мулла вафат була. Гаиләсен сөргенгә җибәрәләр.

Габдуллаҗан 1977 елда вафат була.



# Гатиятуллина Марзия Гатиятулла кызы

**(7.12.1914 –27.07.1983)**

Гатиятуллина Марзия Гатиятулла кызы 1914 елның 7 декабрендә дөньяга килә. 1936 елны Шекшенең Мирзагаян исемле егетенә кияүгә чыга. Сугыш башлангач, ире сугышка киткәндә, 3 яшьлек баласы белән кала. Колхозда ирләр эшен дә, хатын-кыз эшен дә башкарырга туры килә. Сугыш беткәч, ире Мирзагаян исән-сау авылга әйләнеп кайта. Тагын 5 балалары туа. Шулай итеп 5 малай, 1 кыз баланы үстереп, башлы-күзле итәләр. 1983 елның 27 июлендә вафат була.



1962 ел

Нурания апа кулъязмасыннан.

14.04.2016 ел.



# Шаймарданова Бибхания Галимулла кызы

**(23.07.1920 –10.05.2013)**

Шәймәрданова Бибихания Галимулла кызы 1920 нче елның 23 июлендә Саба районы  Алан-Елга авылында Галимулла һәм Миңсылу гаиләсендә  4  нче кыз булып дөньяга килә. Әтисе Галимулла  сәүдә белән шөгыльләнә, һәм ул вакытта аларның гаиләсе авылда яхшы хәллеләрдән санала. Гаилә башлыгы ат белән шәһәргә барып, авыл кешесе өчен кирәк-ярак, азык-төлек алып кайта торган була. Үзләренең тырышлыгы белән менә дигән итеп тормыш алып баралар алар. Ләкин  30 нчы еллардагы репрессия җиле аларның тату гаиләсен дә читләп узмый. Бар булган мөлкәтне, атларын тартып алалар, гомер иткән өйләреннән үк куып чыгаралар, ә иң яманы  “кулак”  дигән исемне күтәрергә мәҗбүр булалар. Тик гаиләдә хезмәт белән тәрбияләнгән кызлар беркайчан да  югалып калмыйлар.  3 класс белеме булган Хания хезмәт юлын бик яшьтән  башлый, үзе шикелле үк кызлар белән Мари якларында урман кисүдә эшли.  Беләкләре ныгымаган, әле  балалыгы да  чыгып бетмәгән кызлар олылар белән беррәттән авыр физик эш башкаралар. Хания Галимулла кызы ул еллар турында  балаларына:   “Бер эштән дә куркып тормадык, нәрсә кушсалар, шуны эшләдек, тип-тигез итеп киселгән агачларны “штабельләп” өеп куя торган идек,” –дип еш сөйли торган була. Бу эш аларны чыныктыра , нык итә. Дәһшәтле сугыш елларында да   Хания авырлыктан куркып тормый, шәһәргә китә.

1943-1947 елларда ул Казанда 16 номерлы моторлар төзү заводында хезмәт куя. Биредә ул көнозын, алны-ялны белми , станок артында эшли , алар Иван исемле рус кешесе белән самолетка клапаннар  әзерлиләр. Менә шулай итеп , иләмсез авыр фидакарь хезмәтләре белән җиңү көннәрен якынайталар.

1947 нче елда Бибихания ,Бөек Ватан сугышыннан бик күп авырлыклар күреп , исән-сау әйләнеп кайткан, авылның иң чибәр , булган егете Миннегали Шәймәрданов белән гаилә корып җибәрәләр. Сугыштан соңгы тыныч елларда алар авылда хезмәт белән яшәп көн итәләр. Гаилә башлыгы ферма мөдире, бригадир кебек җитәкче урыннарда эшли. Хания терлекчелектә, төрле эштә хезмәт куя, бөтен хезмәт кул көче белән башкарыла.

” Зур-зур бочкалар белән елгадан су ташып, учак ягып зур казанда малларга ашарга пешерә идек ,” – дип искә ала ул дуңгыз фермасында эшләгән елларын . Менә шулай колхозда үрнәк эшче дә булалар , гаиләдә үзләре шикелле үк игелекле балалар тәрбияләргә дә вакыт таба бу матур гаилә. Алар 6 балага гомер бирәләр. Бала хәсрәтләре дә татырга туры килә, 3 яше тулган бер уллары каты авырып җан бирә. Калган балалары 1 кыз һәм 4 малай әти-әни үрнәгендә авылда калалар, гаилә корып, барысы да мактаулы хезмәт юлы үтәләр.
Хания һәм Миннегали Шәймәрдановлар 66 ел бергә тигезлектә яшиләр. 2013 елда 93 яшьләренә җитеп, бер-бер артлы дөнья куялар. Хәзерге вакытта балалары барысы да исән-саулар һәм лаеклы ялда. 4 уллары Алан-Елга авылында , 1 кызлары Шекшедә үз гаиләләре белән яшиләр. 15 онык , 22 оныкчыклары бар.
Шәймәрданова Бибихания Галимулла кызына бирелгән хөкүмәт бүләкләре:

- 1959 нчы елда “Ана” медале.
- 1946 нчы елда «Бөек Ватан сугышы елларында фидакарь хезмәте өчен» медале
- 1982 нче елда “Хезмәт ветераны” исеме
- Бөек Җиңүнең 40, 50, 55 еллыкларына юбилей медальләре.

Оныгы Закирова Венера язмасы.





# Халиуллина Марсиля Абдулла кызы

**( ...04.1929 - 18.02.2013)**

## Үзем турында үзем.

Узең турында үзең яза башлагач, әллә ничек, 73 яшеңдә үткән гомереңә кире кайту, аңа күз салу һәм аны йомгаклаган кебек, нәтиҗә ясау була бугай бу.

Безнең гомер бит ул туры килде
Зур тарихи данлы елларга
Искелектән яңалыкка күчкән
Болгавырлы канлы чорларга.

Бөек Октябрь революциясеннән соң, иске тормышны җимереп, яңасын төзеп яткан авыр чор була ул. Кешеләрнең язмышы ил язмышы белән бергә бара бит ул.

Әтием Бөкмеш авылының  Гата мулла малае булса да, яңа җәмгыять төзүдә актив көрәшче була. Ул дөньяны материалистик танып белүче, белемле һәм зыялы кеше иде.

Әнием Өтернәс авылы мулласы кызы, укымышлы һәм бик уңган хуҗәбикә иде.

Мин 1929 нчы елның апрелендә гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килгәнмен.   Ул вакытта без Бөкмештә, хәзерге Кызыл Мишә авылында яши идек.. Минем ике абыем – Хәниф абыем 1921 нче елгы, Мөҗип абыем 1924 нче елгы, Чулпан апаем 1925 елны туганнар.

Ул чорда илдә зур үзгәрешләр булып авыллардагы байлардан калган йортларны сүтеп мәктәпләр итеп төзиләр иде. Әтием шушы эшләрдә актив катнашып Нырты, Ике басу Арташ, Иске Икшермә авылларында яңа мәктәпләр салып, яңача уку укыту эшләрен юлга салып йөрде. Шул сәбәпле без дә гаилә белән күченеп йөрдек. Миңа 3 яшь булганда безнең гаилә атлы

Тагын ике елдан безне Ике басу Арташ авылына күчерделәр. Ул вакытта мәктәпләр раскулачивать ителгән байларның йортларын сүтеп мәктәпләр итеп салына иде. Тагын ике елдан мин 5 яшьлек чакта безне Иске Икшермә авылына күчерделәр. Күчкән бер авыл минем күңелемә бер яңалык белән кереп кала иде. Арташтан без бик яхшы күңелле Кәрим бабайларда тордык. Ныртыда безнең Айсылу исемле сеңлебез үлеп калды.

Тагын ике елдан мин 5-6 яшьләр чамасында без тагын Иске Икшермә авылына күчеп килдек. Анда да мәктәп әле төзелеп кенә ята иде. Мин иң татлы сабый чагым шул Иске Икшермә авылында калды дип сагынам.

Аның Кирәмәт чишмәләре. Ул Мишә суларында су коенып, болыннарында кузгалак ашап аунап үскән сабый чагым шунда калды. Миңзифа апалар йөрәгемдә мәңгегә калдылар. Аларның авылы аша ничек аклар узганын, аның олы кызын ничек көчләп чукындырырга әйтүләрен ул сөйли иде. Аларның арыш оныннан умач уып пешергән итсез ашларының тәмлелеген гомер буе онытмадым. Урыннарыгыз җәннәттә булсын изге күңелле гади кешеләрем.

Мин 1 нче класста шул Икшермә мәктәбендә укыдым. 5 классны тәмамлагач, Бөек Ватан сугышы башланган көнне без гаилә белән Кызыл Мишәгә күченеп кайттык. Ул вакытта Хәниф абыем Новосибирскида Хәрби училещеда укый иде. Мөжип абыем Саба урта мәктәбенең 10 класс укучысы. Әтием белән абыем безнең иске өебезне төзәтеп эшләп, көзгә күченеп кенә калдык.

Мөжип абыем 10 класс укучысы класслары белән үзләре теләп фронтка киттеләр. Әтием карт солдат булып алынды. Без дүрт бала бер әнигә өелеп калдык. Ярый әле авыру олы апам Чулпанны әниемнең сеңлесе Һаҗәр апа тәрбиягә алды. Әниемнең бердәнбер ярдәмчесе булып 5 класс укучысы мин калдым. Сугыш минем ике абыемны алды, кече энем Камил(әтидән туып кына калган иде) өйдә үлде. Әтием карт солдат булып сугышка китте.

Без Кызыл Мишәдән 32 бала Тимершыкка укырга йөри идек. Бер- ике елдан иптәшләр туктап беттеләр. Тормыш йөген без әни белән икәү тарттык. Әни ничек тә минем укуымны дәвам итәргә ярдәм итте.

## Сугышның бик кискен чоры иде.

7нче классны тәмамлагач 1942 елда мин үзебезнең авылда клуб мөдире һәм китапханәче булып эшли башладым. Авылдагы 3 комсомолдан оешма оештырып комсорг булып эшли башладым. Безнең комсомоллар 32 гә җитте. Күбесе сугыштан яраланып кайткан абыйлар иде. Ул вакыттагы авыр кул хезмәте бөтен кешегә дә эләкте. Язгы чәчү өчен 40 чакрым арадан аркага капчык асып язгы суны чабата белән ерып симәнәгә ашлык алып кайткан нык истә калган. Миннән күпкә өлкән апалар белән Кызыл-Мишәнең Көрҗә тау башына кайтып җиттек тә хәл алырга утырдык, үзебез көне буена авызга бер валчык ризык капмаган,сусаган. Торып китә генә алмыйбыз бит,хәл юк.Өйгә кайткач күп итеп су эчтем. Шуның шаукымы гомергә калды,аякларым сызлый торганга әйләнделәр. Кем белгән аны шундый ерак ара үткәч берьюлы күп итеп су эчәргә ярамаганын.

Авыр, ачлы туклы, хәсрәтле сугыш еллары узып китте, 1945 нче елда Бөек Җиңү килде. Оешмага сугыш кырыннан өлкән абыйлар кайтып, дөньялар ямьләнә башлады. Әтием сугыш беткәч 45 нең ноябрендә генә кайтты. 1946 нчы елда Апаста Зиннур жизниләрдә тордым. Бу җизнәбез Апасның 1нче райком секретаре иде. Анда бер ел укыгач, уку елы беткәнче авылга кайтырга туры килде. Шушы елны мин Казан педагогия училищесына укырга кердем. Язга кадәр әйбәт кенә укып торганда җизнәбезне үтерделәр. Апаем мине тагын авылга алып кайтып китте.

Миңа Саба урта мәктәбен тәмамлап ,кабат Казан педагогия училищесына укырга кердем. 1950 елда үз иптәшләрем белән Казан педучилищесына экзаменнар биреп, укытучы исеме алдым,үзебезнең авылга әтием укытучы итеп чакырды.

Өч ел Кызыл – Мишә башлангыч мәктәбендә укытучы булып эшләдем. 1953 нче елдан Шекше сигезьеллык мәктәбендә эшли башладым. 30 ел эшләү дәверендә төрле чорлар кичерергә туры килсә дә, мин балаларны, эшемне яраттым.

Эшемне зур бәяләделәр. Мин мәгариф отличнигы һәм РСФСРның мактау грамотасы белән бүләкләндем. 33 ел эшләү дәверендә укыган укучыларым бик мактаулы эшләр башкарулары белән мин бик бәхетлемен. Хәерле гомер сезгә газизләрем.



Ярты гомерем синдә үткәнгә
Һич үкенмим минем мәктәбем
Бары синдә таптым яшәвемнең
Бөтен ямен, бөтен мәгънәсен.

Төннәрендә керә төшләремә
Сагындырып мәктәп баласын.
Син бит мине шулай төшләремдә.
Картлыгыма озата барасың.

Сиңа килгәч күңелләр җилкенә,
Яшәргәндәй булып каласың.
Мәктәп бит ул кояш, язлар иле.
Ташып тора яшьлек авазы.

Аяк басып кергән сабыйлар бит
Ун ел буе синдә үсәләр.
Вакыт җиткәч, алар очар коштай
Канат ярып ерак китәләр.

Бүген дә бит килдек сагынып сиңа
Хушлашырга якын дусларым.
Онытмаслар алар, онытмаслар,
Гөрләп торган мәктәп елларын.

Ак юл телик әйдә без аларга
Исән-саулык телик тагын да.
Каушамыйча җиңеп үтә алсыннар.
Авырлыклар килгән чагында.

25 май, 1990 ел.

1996 нчы елда Шекше авылында үткәрелгән җыен
уңаеннан язылган.

## Авылымны яратам.

Үрләреңә менсәм күз алдында
Җәелеп ята изге кырларың.
Урманнарың синең, үзәннәрең
Еракларга киткән юлларың.

Юлларыңа карап уйга калам
Гасырларга чигенә уйларым.
Көнчыгышка фоэтоннар белән
Әби патша үткән юлларың.

Илле елга чигенәм, шул юллардан
Ил сакларга киткән ирләрең.
Чит җирләрдә газиз башын салып,
Кайта алмыйча калган улларың.

Әле дә бит шул юлларга карап
Сезне көтә газиз аналар.
Чит җирләргә бәхет эзләп китеп,
Чәчелде бит безнең балалар.

Бормаланып аккан Мишә суың
Ярларында бөдрә таллары
Шул талларны сагынып һәр яз кайта
Кәккукләре, сандугачлары.

Кырларыңда шыткан һәр бөртегең
Сугарылган маңгай тиренә.
Шуңадырмы бик – бик газиз алар
Эш сөючән авыл иренә.

Чит җирләргә чыксам, ярты җаным
Бүленеп калган кебек Шекшедә.
Гомер узган саен көчле миндә
Сиңа булган сөю хисе дә.

Телим, Шекшем, һәрчак тыныч тормыш
Шат авазлар тынып тормавын.
Мәктәпләрең тулы балаларың,
Амбарларың тулы икмәгең,
Эш сөючән уңган халкың белән
Атсын синең алсу таңнарың

1 июнь, 1996 ел.

**Солдаттагы улы Алмазга багышлана.**

Син киткәч яшәргән бакчалар
Хуш исле гөлләргә күмелде.
Һәр таңда мөлдери тажлары
Алар да сагыналар түгелме.

Өс башың кадерләп, үтүкләп,
Сандыгым төбенә салынды.
Көтәләр син алып кигәнне
Алар да бит сине сагынды.

Тик берсен юмыйча калдырдым
Сагынган чагында иснәргә
Тын гына күз яшем тамызам,
Сагындым бит, улым, нишләргә?

Бәйрәм көн булганда шау килеп
Туганнар җыела табынга
Өстәлнең бер башы буш кала.
Табын да бит сине сагына.

Кайгырма, әни, дип язасың
Кайгырмыйм да кебек үземә.
Тик ана йөрәге шундый ул
Сагынудан яшь тула күземә.

Теләгем шул сиңа, Алмазым,
Хезмәтең булсын гел уң гына
Исән-сау кайт, улым, сагындым
Әниең теләге шул гына.
20 апрель, 1990 ел.

# Ветераннар.

Ветераннар, ветераннар алар
Чал тарихның җанлы шаһиты
Кайтавазы үткән давылларның
Замананың җырчы шагыйре.

Сирәгәя бара безнең сафлар
Берәм-берәм китә арадан.
Әле һаман кан саркытып тора
Йөрәктәге тирән яралар.

Бүгенгенең кадере булыр микән,
Үткәннәрне әгәр белмәсәк.
Бөек чорның данлы батырлыгын
Киләчәккә алып килмәсәк.

Сөйләгез сез килер буыннарга
Үткәннәрне искә төшереп
Ветераннарның тирән борчылуын
Күңелендә йөртсен кешелек.

Аваз салыйк бөтен планетага
Тынычлыгын беләп дөньяның
Мәңге яшәр ветераннар даны
Мәңге яшәр җирдә уяулык.

Гомер узган саен ныграк әрни
Ул чорларда күргән яралар.
Алар шулай һаман кабатланып
Соңгы юлга озата баралар.

Укытучылар көненә багышлана

**Әрсезләнеп килә картлык**
Балачагым һаман саен
Якыная күңелгә.
Күңел белән шул чакларга
Юлга чыгам бүген дә.

Тирбәләм төннәр буе
Сабый чак бишегендә.
Бапла чак гүзәллегенә
Калмаган бер шигем дә.

Үткәнемә йөзеп китәм
Хыяллар дәрьясында.
Уңышлары, ялгышларым
Калкып чыга барсы да.

Атлап йөрим төннәр буе
Гомер сукмакларыннан.
Качып котылырга телим
Картлыгым таңнарыннан.

Әрсезләнеп килә картлык,
Килә көнләп, сәгатьләп.
Алырга теләп көчемне,
Якаларга исәпләп.

Тыныч килсен картлыгың дип,
Теләгәннәр гомергә.
Ләкин әле күңелкәем
Тыныч түгел шул бер дә.

Илкәемнең хәле авыр,
Упкын читендә генә.
Бер ялгыш адым ясалса
Яхшыга булыр димә.

Ышанасы килә ләкин
Яхшылык җиңәсенә.
Безнең буынга бәхетле
Картлыкның киләсенә.

Шундый ак өметләр белән
Аттырам таңнарымны.
Балачак хәтирәләре
Дәвалый җаннарымны.

“Саба таңнары” газетасыннан
09.02.1991(язылган)

# Халиуллин Равил Зариф улы

**(5.01.1928—29.05.2003)**

Халиуллин Равил Зариф улы – минем әтием. Ул 1928 елның 5 гыйнварында Саба районы, Шекше авылында туа. Шекше җиде еллык мәктәбен тәмамлый. Бөек Ватан сугышы башланганда әтигә унөч яшь тулган була. Ул чордагы яшүсмерләргә авыл хуҗалыгындагы барлык эшләрдә дә хезмәт куярга туры килә. Әти сугыш вакыты турында бик күп сөйләми иде. Шулай да ындыр табагыннан Шәмәрдән элеваторына ашлык ташыганнарын сөйләгәне бар. Алар, чабата кигән ундүрт-унбиш яшьлек малайлар, таң яктысы беленә башлауга, кичтән ындыр табагында ат арбасына төяп, әзерләп куелган ашлыкны, ат җигеп элеваторга алып киткәннәр, капчыкларны үлчәтеп, складларга ташып бушатканнар. Көн әйбәт булганда өчешәр тапкыр менә идек дип сөйләгән иде әти. Шулай итеп кабат караңгы төшкәнче юлда. Тик яшьлек үзенекен итә, өйгә кайтып ашап алгач клубка кичке уенга чыга идек. Арып-талып өйгә йокларга кайткач аяктан чабатаны сүтеп тормыйбыз чөнки өч-дүрт сәгать йокы вакыты калган була. Таң белән кабат чыгып китәргә кирәк. Бер вакыт аларның ике капчык ашлыклары тулмый. Күп тикшереп тормыйча гаепне шушы ике егеткә ягалар һәм әтием авылдашы Вәгыйз белән ике ел Кузбасста шахтада эшләп төрмә срогы үтә. Башка истәлекләре хәтердә калмаган. Әтием сугыш тәмамлангач армия сафларына алына. Кытай-Корея сугышында зениткада дальномерчик булып катнашырга туры килә аңар. Совет солдатларын ул вакытта Кытай хөкүмәте яхшы тәрбияли. Әти –“Өстәлдә ипи бер тарелка итеп кисеп куела, тавык итләре ашаталар дип сөйләгәне бар. Сугыш вакытындагы ачлы-туклы яшәүдән соң аларга мондый тормыш гаҗәеп тоелгандыр. 1954 елда, әтием Шекше мәктәбенә укытучы булып килгән Кызыл-Мишә кызы Гатауллина Марсилә белән гаилә корып җибәрәләр һәм безне, биш баланы дөньяга китереп, тәрбияләп үстерделәр. Без аларга бик рәхмәтлебез. Бар булганы белән безне тәрбияләп, какмый-сукмый яратып үстерделәр. Әти-Әни безне намуслы булып, кеше хакына кермичә, үз хезмәтебез белән яшәргә өйрәттеләр.

Әтием Равил 2003 нче елның 29 маенда гур иясе булды һәм Шекше зиратына җирләнде.

2016 ел,11 апрель. Сафина Наилә Равил кызы.

# Сафина Гөлбикә Шәймәрдән кызы

**(......1912– 4.08.1999)**

Сафина Гөлбикә 1912 елда Алан-Елга авылында Шәймәрдән бабай гаиләсендә туа. Яшьли әнисез кала. 1933—1934 елларда тракторчы егет Сафин Хариска кияүгә чыга. Сугыш башланганда, аларның дүрт балалары туган була инде. Харис 1941 елда ук сугышка алына. Сугыш вакытында аларның Вәгыйз һәм Марсель исемле ике өлкән баласы ачлыктан вафат булалар. Гөлбикә әби җәен кырчылыкта эшли, кыш көне әвеснектә ашлык суга. Ул вакытта барлык эшләр кул көче белән башкарыла. Ул вакыттагы иң авыр эшләр ирләре сугышка киткән хатыннар җилкәсенә төшә. Алар, тырышып эшләп, җиңү көнен якынайтырга тырышалар. Гөлбикәнең Харисыннан гына хатлар килми. Ул 1941 елнын август аеннан пленга эләгә. 1943 елда ике иптәше белән пленнан качалар. Кабат фашистлар кулына эләкмәс өчен , 4 тәүлек буе су эчендә камыштан сулап качып яталар. Кабат үзебезнекеләр ягына чыгып, 1945 елда туган якларга кайта. Алар Гөлбикә белән 10 балага гомер биргән кешеләр.Сугыштан соң алар барлыгы 12 ел яшәп калалар. Тракторчы Харис, суыкларда трактор ремонтлап салкын тидереп ,1957 елда вафат була. Гөлбикә балаларын исән-сау үстереп, 85 яшенә кадәр яши. 1999 нчы елның 4 августында гүр иясе була һәм Алан-Елга зиратына җирләнелә.

Истәлекләрне Гөлбикә әби кызы Хафизова Хаҗирә апа сөйләгәннәрдән төп йортта яшәүче киленнәре Сафина Наилә язып алды.

# Яруллина Гайшә Мифтах кызы

Сугыш башланганда, Гайшә 13 яшьтә була. Бөтен авыл буенча таралган дәһшәтле хәбәр авыл халкын борчуга сала: ”Сугыш башланган!”. Бөтен кеше ,эшен ташлап ,колхоз идарәсе каршына җыелышкан , авыл халкы ыгы-зыгы килә, елашалар.

Авылдагы ирләрне военкаматка чакыра башлыйлар. Бөтен авыл халкы сугышка китүчеләрне озатып калалар .

Аның Даут абыйсы ул вакытта Ижевскийда армиядә була, шуннан сугышка алына . Даут абыйларыннан хат килеп торган . Аның ике аягыда җәрәхәтләнә ,бик озак госпитальдә ята һәм авылына кайта. Даут абыйсын Гайшә ,үзе ат җигеп ,Шәмәрдәннән менеп ала. Зур абыйлары Габделбәр бик авырту була , башта аны сугышка алмыйлар . Сугыш бетәр алдыннан, кеше санын тутырыр өчен ,аны сугышка алалар. Ул китеп озак та үтми аларга Габделбәр хәбәрсез югалды дигән хат килә. Гайшәнең әтисе сугыш башланганчы ук үлгән була. Әниләре сыерларын авыр булса да бетерми асырый, шул сыер булганлыктан ,алар бик ач булмый. Авылларында, ачка чыдый алмыйча,агулы үлән ашап үлүчеләр була.
Гайшә авылларына нинди эш булса, барысына башкалар белән бертигез эшләгән. Бу канкойгыч сугышның бетүен бик көтәләр. Ниһаять, озак еллар көткән куанычлы көн -Җиңү көне килеп җитә.

Гайшә апа тормыш иптәше белән сугыш беткәч таныша. Ул- Шекше егете Яруллин Йосып Гайсә улы була, алар 1956 ела өйләнешәләр. Йосыпның әтисе Яруллин Гайсәне сугышка алалар (1901елга) ,бер генә хаты килә дә аннан соң хәбәрсез югала. Шулай ук, Гайсәнең абыйсы Яруллин Ибраһим хәбәрсез югала.

Бүгенге көндә Гайшә апа төп йортта улы Илшат, килене Люция тәрбиясендә яши.

# Сәйфетдинов Габдулла

| Язып алу вакыты | Сөйләүчеләр | Язып алучы |
|---|---|---|
| Март, 2015 | Сәйфетдинов Вагыйз Габдулла улы (21.12.1935) Шекше авылы<br>Хисмәтова Нәсимә Габдулла кызы (20.06.1943) Шекше авылы | Шекше мәдәният йорты мөдире Ләйсән Хисмәтова |

**Вагыйз абый сөйли**: “Минем әтием Сәйфетдинов Габдулла Сәйфетдин улы 1906нчы елны туган. Шекше авылыныкы. Ул Сәйфетдин бабайның икенче хатыны Бибигайшәдән туган. Аның бертуганнары-Бәдерниса һәм Фәйзулла (Вәлиева Зәйтүнәнең әтисе). Сәйфетдин бабайның беренче хатыны үлгән, аннан- Бибиниса (Мөбәрәков Газинурның әбисе),Әсматтә (Олыяз авылында яшәде), Газизә (ул үлгән), Сәйфулла туып калган була.

Әти сугышка киткәнче , без өч бала Кәүсәрия апа (1932нче елгы), мин һәм энебез Нәсим(1940нчы елгы) туып калганбыз. Энебез Нәсим өченче сыйныфта укыганда вафат булды( бер елны көз көне бик каты ташу булды, мәктәп янындагы елгада бозлар кузгалып, алар малайлар белән шулар өстенә кереп уйныйлар да Нәсим боз астына китеп үлә, гәүдәсен әллә ни ерак та түгел мәктәп почмагыннан гына табып алдылар).

1941нче елны сугыш чыкты. Без әниләргә ияреп әтиләрне сугышка озатырга бардык, зиратка кадәр төштек. Әтиләрне атка утыртып алып киттеләр, бу көзгә таба булгандыр. Сугыш вакытында безнең авылга эвакуацияләп кешеләр кайтарта башладылар. Мәскәү шәһәреннән килгән өч маржа безнең белән Чытыр Гарифуллалар арасындагы Хөснетдиннәр йортында яшәделәр. Алар кирәк-яракка гел безгә керәләр иде. Сугыш беткәч, рәхмәтләрен әйтеп, кире үз шәһәрләренә кайтып киттеләр.

Әти сугыштан имгәнеп кайтты, бер аягы бөгелми, туры гына тора иде, ул култык таяклары белән йөрде. Әти кайткач, 1943нче елны Нәсимә туды, аннан соң әле энекәшләр дә туды, тик алар озак тормый үлеп бардылар.

Әтиебез сугыштан исән кайтты, тик безгә ана назын озак татырга насыйп булмады. Әниебез Бибинур Әхмәтша кызы (Әхмәтшиннар нәселеннән иң кечесе) 1947нче елны авырып дөнья куйды. Әни вафат булгач, әтиебез Алан -Елга авылыннан Рәхимә карчыкка өйләнде. Аның ире сугышта үлгән, балалары булмаган. Безгә килгәч тә ул бала тапмады."

***Нәсимә әни сөйли:*** "Безнең әти сугышка кадәр совхоз умартачылыгында эшләгән. (Алан-Елга ягында урман буенда "Совхоз чишмәсе" бар). Кәүсәрия апай шунда әтигә ияреп баргалый идем дип сөйли иде.

Әти сугышка алынгач, йөгерә-йөгерә урман эчләреннән, сазлыклардан йөрдек дип сөйли торган иде. Башта мари урманнарында ятканнар, урман кискәннәр дип беләм. Аның тез башына пуля тигән, ул яраланганын белмәгәгән, барабыз-барабыз, итек эченә су тулды дип торам, ул кан булган икән дип сөйли иде әти. Аннары госпитальгә эләккән, шуннан соң култык таякларына таянып авылга кайткан."

***Вагыйз абый сөйли:*** "Сугыштан имгәнеп кайткач, әти умартачылык эшенә тотынды. Безнең янда гына, буш тора торган йорт урынында подвалы да бар

иде. Шуннан умарталарны ат белән Иштуганга якын урнашкан "Нариман" совхозы умарталыгына илтәләр иде. Гайшә әбиләрнең (әтинең әнисе) үз умарталары бар иде. Әби безгә шуннан бал каезлап алып керә иде. Аларның әле "Багана умарталары" булганын да хәтерлим (ул агач куышыннан ясалган).

***Нәсимә әни сөйли***: "Әтиебез бөтен эшкә булган кеше, балта остасы да, пич чыгаручы да ул. Матур итеп чаналар, арбалар, дугалар ясый иде колхоз атларына. Җәй көннәрен инешкә кабык салып, мунчала төшерә, аны киптерә. Кыш буе шуннан колхозга дип аркан ишә иде.

***Вагыйз абый сөйли:*** Ул вакытта безнең йорт Газизов Нияз тыкрыгыннан аскарак төшкәч, имән агачы янында иде. Анда ике йорт булып, аларны өйалды тоташтыра иде. Ниязлар яши торган урында да безнең тагын бер

Хәзерге йортны салганда, әти авырту иде инде, ул 1960нчы елда үлде. Пенсиягә чыгып озак та тормады. Әни кебек әти дә печән өсләрендә җәй көне үлде. Әтинең бер медале бар иде, ул хәзер югалган инде.

Мин армиягә киткәндә , әти мине Сабага ат белән озатты. Без күрше Нурихан белән бергә хезмәт иттек. Сабадан Шәмәрдәнгә, аннан поезд белән Казанга киттек.  Олыязда әтинең апасы Әсмабикә яши иде. Әтинең әнисе Гайшә әби мине ,үзе белән иптәш булыр дип ,Шәмәрдән, я Иштуганга ипи алып кайтырга алып китә иде, без кайвакыт Әсма апаларга да кереп чыга идек. Ипи чиратында бик озак кысыла-кысыла торабыз, берзаман “Ипи бетте” дип кибетче кычкыра. Ул елларда каен, җир җиләкләрен җыеп , Шәмәрдәнгә алып менеп ,бер стаканын 20 тиенгә саталар иде.

***Вагыйз абыйның мәктәптә укыган еллары.*** Мин 7-8 яшьләрдә укырга кердем. Әти фанердан кагып портфель ясап бирде. Нәрсә туры килсә, шуның белән яздык. Өскә дә, аякка да алама киемнәр булды инде.  Шекше мәктәбе бик зур иде. Аның югары өлешендә детдом оештырдылар, аскы өлешендә башлангыч класслар укыды. Без детдом балалары белән бергә укыдык. Мин 7нчене бетереп чыктым. Хәтеремдә калган вакыйга: 1953нче елның март айлары тирәсе, Сталин үлгән дип укытучылар елады.

***Авыл тарихына кагылышлы мәгълүматлар Вагыйз абый сөйли:*** “Хәзер Гарипов Илназ кибете урнашкан урында мәчет бар иде, аның янында юкә, нарат агачлары үсә иде, наратның берсе әле бүген дә бар. Шул мәчет астында сепарат бар иде, без әниләр белән шунда сөт аертырга йөрдек. Бөтен авыл халкы шунда килә иде. Мәчет янында гына коесы да бар иде.

Мәчет соңыннан бик озак кына клуб булып торды. Анда башта тавышсыз кино күрсәтәләр иде. Аннары башка төрлесе инде. Авыл яшьләре, шунда килеп ,гармун көйләренә уйныйлар иде. “Назалы”, “Парлы” уеннар.

Галләм дигән кешенең йортында да сепарат аерттылар.

Хәзер Фатыйхов Маратлар яши торган йорт бакча башында амбар бар иде, аны һәр хуҗалыктан келәтләрен җыеп эшләгәннәр.